КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 9 ноябрь г.Казань № 1003

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татар Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүнең 100 еллыгын әзерләү һәм бәйрәм итү чаралары планын раслау турында» 2016 ел, 28 декабрь, 1020 нче карары белән расланган Татар Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүнең 100 еллыгын әзерләү һәм бәйрәм итү чаралары планына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүнең 100 еллыгын әзерләү һәм бәйрәм итү чаралары планын раслау турында» 2016 ел, 28 декабрь, 1020 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 15 май, 289 нчы; 2018 ел, 7 февраль, 64 нче; 2018 ел, 4 июль, 548 нче; 2019 ел, 2 декабрь, 1087 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүнең 100 еллыгын әзерләү һәм бәйрәм итү чаралары планына, 1 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 50.5 – 50.9 нчы пунктлар өстәп, үзгәрешләр кертергә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «50.5. | «ТАССРның 100-еллыгы исемендәге 220 кВлы Зеленодольск ярдәмче станциясе» дип аталган ярдәмче станция ачу | 2020 ел | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте (килешү буенча) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 50.6. | Татарстан Республикасының әйдәп баручы театр коллективлары тарафыннан театр спектакльләрен булдыру | 2020 ел | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы |
| 50.7. | Фестивальләр, конкурслар, иҗат кичәләре, лабораторияләр, концертлар, белем бирү проектларын оештыру һәм үткәрү, матди-техник базаны оештыру, ныгыту, мәдәният эшлеклеләренең истәлеген мәңгеләштерү, истәлекле даталарны бәйрәм итү (аерым план буенча) | 2020 ел | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасының дәүләт мәдәният учреждениеләре, Татарстан Республикасының иҗат берлекләре (килешү буенча) |
| 50.8. | Татарстан Республикасының ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелгән мәдәни мирас объектлары территориясендә урнашкан музей экспонатларының сакланышын гамәлгә ашыру буенча чаралар үткәрү | 2020 ел | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы |
| 50.9. | Халык сәнгать кәсепләрен үстерүгә юнәлдерелгән республика чараларын оештыру һәм үткәрү | 2020 ел | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин